ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль, 2019 ел № 30/6

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, 2017 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 463-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11 санлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктта:

– 10 пунктчада «урыны» сүзеннән соң «(мәйданчыгы)» дип өстәргә;

– түбәндәге эчтәлектәге 35-38 пунктлар өстәргә:

«35) якын-тирә территория – мондый җир кишәрлеге булдырылган һәм чикләре Татарстан Республикасы законы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре белән билгеләнгән очракта, бина, корылма, җир участогы янындагы гомуми файдаланудагы территория;

36) тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорт) – Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән расланган тышкы мәгълүмат чараларының тышкы кыяфәтен һәм урнашу урынын

билгеләүче һәм аны идентификацияләү өчен кирәкле башка белешмәләрне туплаган аерым билгеләнгән формадагы документ;

37) тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасы (элмә) – «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 маддәсе нигезендә мәҗбүри булган мәгълүматны (оешманың исеме (фирма исеме), аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы, шулай ук закон нигезендә яйсә эш буенча урнаштырылып, реклама белән бәйле булмаган мәгълүматны) кулланучыларга җиткерү максатында бина һәм корылмаларда, шул исәптән капиталь булмаган корылмаларда, оешмалар һәм (яки) товар реализациясе урынында урнаштырылучы мәгълүмат конструкциясе;

38) Объектта реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясе – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының вәкаләтле органы тарафыннан төзелешнең тышкы архитектурасын саклау кирәклеген исәпкә алып, реклама конструкцияләрен һәм биналарның фасадларында тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру вариантлары нигезендә эшләнгән аерым объектта (бина, корылма янындагы җир кишәрлегендә тышкы мәгълүмат чаралары билгеләнгән очракта, бина, корылма, яндагы территория белән корылма) реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты.»;

2) 9 пунктны түбндәге эчтәлектәге 20-22 пунктчалар белән тутыландырырга:

«20) инженер-техник тәэмин итү челтәрен проект документларсыз салу, җир астыннан үткәрмәү;

21) әлеге максатчан билгеләнештә булмаган җир участокларында транспорт чараларын кую урыны булдыру;

22) әлеге максатчан билгеләнештә булмаган җир участокларында стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру.»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 33.1, 33.2 пунктлар белән тутыландырырга:

«33.1. машина кую урыннары һәм алар янындагы территорияләрне карап тоту 113.13330.2016 СП нигезендә, шулай ук әлеге Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.;

33.2. Әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар:

1) машина кую урыннарында санитар нормаларны һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәргә тиеш. Әйләнә-тирә территорияне даими рәвештә санитар чистартырга, чүп контейнерлары (урналар) урнаштырырга, каты коммуналь калдыкларны, карны даими чыгаруны тәэмин итәргә тиеш;

2) машина кую урыннарында автомобиль юуны, ягулык-майлау материаллары агып торган автомобильләрне куюны тыярга тиеш;

3) машина кую урыннарында башка капиталь һәм вакытлыча биналар, корылмалар, стационар булмаган сәүдә объектлары, объект

проекты белән каралмаган өскормалар төзелешенә юл куймаска тиеш;

4) машина саклау урынында һәм аның янәшәсендәге территориядә материаллар туплауга, тулы комплектта булмаган транспорт, төрле конструкцияләр саклауга юл куймаска тиеш;

5) билгеләнгән территориядә булган корылмаларны вакытында ремонтларга һәм буярга тиеш.»;

4) 42 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Биналарда, корылмаларда урнашкан урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләрендә, шулай ук фасадлары урам һәм гомуми шәһәр юлларына чыга торган биналардагы күрсәткечләрдә мәгълүмат Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә языла.»;

5) 58 пунктта «коммуникацияләр» сүзен «коммуникацияләрендә»; дип үзгәртергә;

6) түбәндәге эчтәлектәге 61.1 пунктын өстәргә:

«61.1. Вокзалларда, пристаньнарда, базарларда, аэропортларда, паркларда, ял итү зоналарында, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә һәм гражданнар күпләп була торган башка урыннарда, урамнарда, шул исәптән шәхси йортлар урнашкан урамнарда, торак йортлар подъездларында, шәһәр пассажир транспорты тукталышларында, сәүдә объектларына керү юлында, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларында һәм башка объектларда урналар куелырга тиеш.».

7) 115 пунктта «мәгълүмат конструкцияләрен (алга таба – элмә такталарын)» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 116 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«116. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруны тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорт) һәм урнаштыру концепциясе нигезендә, объектта реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру хокукын бирүче килешү вакытына, ләкин биш елдан артык булмаган чорга, гамәлгә ашыру тәкъдим ителә.

Биналарның фасадларында тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру вариантлары һәм тышкы мәгълүмат чараларына таләпләр Башкарма комитет карары белән раслана.

Тышкы мәгълүмат чарасы Паспорты тышкы мәгълүмат чараларынын реклама конструкцияләрен урнаштыру концепциясенә туры килмәгән очракта һәм (яки) әлеге объектта урнаштыру хокукы бирә торган килешүнең гамәлдә булу вакыты тәгәлләнгән очракта юкка чыгарыла.»;

9) түбәндәге эчтәлектәге 116.1. пунктчасын өстәргә:

«116.1. Объектта реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннары объектта реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру концепциясе белән билгеләнә.»;

10) 117 пунктта:

– «Реклама конструкцияләре» сүзләреннән соң «һәм тышкы мәгълүмат чаралары» сүзләрен өстәргә;

– түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

«Реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын проектлау, әзерләү һәм урнаштыру, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен исәпкә алып, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры китереп башкарылырга тиеш.»;

11) 119 пунктта «реклама конструкцияләре» сүзләреннән соң «һәм тышкы мәгълүмат чаралары» сүзләрен өстәргә;

12) 120 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«120. Тыела:

1) Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан бирелүче реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт кәгазе алмыйча реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү;

2) Башкарма комитетның вәкаләтле органы белән килештерелмәгән тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектыннан (паспортыннан) башка тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру;

3) Башкарма комитетның вәкаләтле органы белән килештерелгән тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектына (паспортына) туры килми торган тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру;

4) зыян күргән (сурәтләр, язулар һәм башка бозулар) реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын ике көннән артык эксплуатацияләү;

5) механик зыян күргән (конструкциянең деформациясе, зарарланган щит һәм башкалар) реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын ике тәүлектән артык эксплуатацияләү,

6) күчмә реклама конструкцияләре (штендерлар) урнаштыру;

7) мәгълүмати-басма продукцияне әлеге максатларда билгеләнгән конструкцияләрдән башка урынга урнаштыру;

13) 121 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

14) 122 пунктның икенче җөмләсен гамәлдән чыккан дип танырга;

15) түбәндәге эчтәлекле 122.1. пунктчасын өстәргә:

«122.1. Тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләре нигезендә урнаштырылырга тиеш.

Ике һәм аннан да күбрәк тел кулланган очракта, текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш, дөрес һәм ачык итеп эшләнгән булырга тиеш.»;

16) түбәндәге эчтәлекле 129.1.-129.6 пунктларын өстәргә:

«129.1. Муниципаль берәмлек территориясен бәйрәмчә бизәү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары

белән дәүләт һәм шәһәр бәйрәмнәре, истәлекле вакыйгаларга бәйле чаралар үткәрү чорында башкарыла.

129.2. Биналар, корылмаларны бизәү муниципаль берәмлек территориясен бәйрәмчә рәсмиләштерү концепциясе кысаларында аларның хуҗалары тарафыннан башкарыла.

129.3. Гомумшәһәр тантаналары һәм бәйрәм чараларын үткәрүгә бәйле эшләр оешмалар тарафыннан үз акчалары хисабына, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты белән килешүләр буенча, муниципаль берәмлек бюджетында әлеге максатларга каралган акча хисабына тормышка ашырыла.

129.4. Бәйрәмчә бизәлеш ясаганда милли флаглар, лозунглар, гирляндалар, паннолар элү, декоратив элементлар һәм композицияләр, стендлар ясау, киосклар, трибуналар, эстрада урнаштыру, шулай ук бәйрәм иллюминациясе тәкъдим ителә.

129.5. Бәйрәм бизәлеше концепциясе Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан расланучы чаралар программасы, объектларны һәм бәйрәм бизәлеше элементларын урнаштыру схемасы белән билгеләнә.

129.6. Бәйрәм бизәлеше элементларын әзерләгәндә һәм урнаштырганда, юл хәрәкәтен җайга салу техник чараларын алырга, аларга зыян салырга һәм аларны күрү мөмкинлеген киметергә ярамый»;

17) 145 пунктны түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: «шулай ук ордерда күрсәтелгән махсус таләпләрне бозмыйча.»;

18) түбәндәге эчтәлектәге 173.1 пунктын өстәргә:

«173.1. Җир эшләре башкаруга ордер ордерда күрсәтелгән вакытта ябылырга тиеш.»;

19) 199 пунктта түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Түбәдән көрәп төшерелгән яки оешма территорияләреннән, төзелеш мәйданчыкларыннан җыелган карны явым-төшем беткәннән соң 24 сәгать эчендә чыгарырга кирәк. Карны җәмәгать файдалану территориясенә чыгару тыела.»;

20) V кисәкне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V кисәк. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруда гражданнарның һәм оешмаларның катнашу тәртибе.

227. Гражданнар махсус һөнәри әзерлек таләп итми торган эшләрне башкаруга җәлеп ителергә мөмкин. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү эшләрен башкаруга Яр Чаллы шәһәренең хезмәткә сәләтле балигъ булган кешеләре төп эштән яки укудан буш вакытларында түләүсез нигездә җәлеп ителә ала. Шул ук вакытта, эш вакыты дүрт сәгатьтән артык була алмый.

228. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү эшләрен башкаруга гражданнарны җәлеп итәсе көнгә

кадәр егерме көннән дә соңга калмыйча шәһәр хакимияте бу хакта түбәндәге ысуллар белән хәбәр итә:

1) шәһәр хакимиятенең рәсми порталында тиешле белдерүләрне урнаштыру;

2) шәһәр җирле үзидарә органнары актлары басылып чыга торган рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында белдерү бастырып чыгару;

3) җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмати стендларда (такталарда) игъланнар урнаштыру;

4) милекчеләренең гомуми җыелышлары карарлары белән билгеләнгән күп фатирлы йортлар биналарында һәм милекчеләр өчен уңайлы урында (подъездларга керү ишекләре янындагы мәгълүмат такталарында) хәбәр урнаштыру;

5) һәм башка ысуллар белән.»;

12) түбәндәге эчтәлектәге VI кисәкне өстәргә:

«VI кисәк. Төзекләндерү нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүгә контроль.

229. Әлеге Кагыйдәләрне бозган өчен гражданнарны, вазыйфаи һәм юридик затларны җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә башкарыла.

230. Гамәлдәге законнар һәм әлеге Кагыйдәләр нигезендә җаваплылык чаралары куллану Кагыйдәләрне бозган гражданны аның тарафыннан китерелгән матди зыянны каплау бурычыннан азат итми.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ